| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ШЭРЛЭРЭМЭ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 август 2026 ел № 10

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү учакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары турында**

Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты наркотиклы кыргый үсемлекләр учаклары таралуны булдырмау максатларында карар итә:

1. Кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрне ачыклау һәм юкка чыгару буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча эшче төркем турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Территориядә кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрнең үсү учакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары планын Шәрләрәмә авыл җирлегенең 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.
4. Шәрләрәмә авыл җирлеге торак пунктларында яшәүчеләрнең, шәхси эшмәкәрләрнең, авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы барлык милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләренең игътибарын үзләрендә файдаланудагы кишәрлекләрдә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү учакларын юкка чыгару буенча чаралар күрү зарурлыгына юнәлтергә.
5. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә һәм «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтта бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Н.Н.Хуҗина

Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 27.08.2026 № 10 карарына 1 нче кушымта

**Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә кыргый, наркотиклы үсемлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча эшче төркем составы**

Эш төркеме рәисе:
Хуҗина Наилә Наил кызы-Шәрләрәмә авыл җирлеге җитәкчесе
Эшче төркем секретаре:
Әхмәтшина Розалия Фоат кызы-Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре
Эшче төркем әгъзалары:
Хәлиуллина Сәрия Азат кызы-Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры
Салихҗанова Мәйсәрә Рәис кызы-Шәрләрәмә ФАП мөдире (килешү буенча)
Сафин Рәсим Вазагетдин улы-полициянең участок уполномоченные (килешү буенча)
Җирле үзидарә органының җир төзелеше өлкәсендәге функцияләрне башкаручы вазыйфаи затларының эш төркеме составына, полициянең участок уполномоченные килешүе буенча, муниципаль наркотикларга каршы комиссиянең вазыйфаи затын, казачество оешмалар вәкилләрен кертү тәкъдим ителә.
Искәрмә: эш төркеме составына Башкарма комитет җитәкчесе буйсынуындагы булмаган гражданнарны (иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар вәкилләрен) һәм вазыйфаи затларны керткәндә "(килешү буенча) " формулировкасы өстәлә

Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 27.08.2026 № 10 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман районы Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә наркотиклы кыргый үсемлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча эшче төркем турында

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Кыргый үсә торган наркотикларны ачыклау һәм юкка чыгару буенча эшче төркем Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендәге үсемлекләр (алга таба-эшче төркем) коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә федераль кануннарга, Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив актларына һәм шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Эшче төркем үз эшчәнлеген Сарман муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән берлектә алып бара.

II. Эшче төркемнең максатлары һәм бурычлары.

4. Эшче төркемнең максаты Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә наркоманияне кисәтү, наркотик матдәләрнең, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору мәсьәләләрендә хокук саклау органнарының һәм җәмәгать оешмаларының көчләрен берләштерүдән гыйбарәт

5. Эшче төркемнең төп бурычлары булып:

- Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә урнашкан иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән наркотик матдәләрнең, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы үзара хезмәттәшлеген оештыру;

- законсыз чәчүлекләрне, наркотиклы кыргый үсемлекләрне үстерү учакларын ачыклау өчен җирләрне, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләрен вакытында һәм сыйфатлы тикшерү, мондый мәйданнарның күләме турында актлар төзү;

- Шәрләрәмә авыл җирлеге хакимиятендә гражданнардан законсыз чәчү урыннары йә наркотиклы кыргый үсемлекләр үсү турында хәбәрләр кабул итү максатында ышаныч телефоны эшләвен тәэмин итү;

- законсыз чәчүлекләр, наркотиклы кыргый үсемлекләр үсү учаклары ачыкланган җир кишәрлекләре милекчеләрен (арендаторларын, файдаланучыларын) билгеләү;
- җир кишәрлекләреннән файдаланучыларга һәм вәкаләтле органнарга законсыз чәчүлекләрне, наркотиклы кыргый үсемлекләрне үстерү учакларын юкка чыгаруда ярдәм күрсәтү;

- наркотиклы үсемлекләрне законсыз үстерүгә, шулай ук наркотиклы үсемлекләрне юкка чыгару чараларын күрмәүгә бәйле җаваплылык мәсьәләләре буенча халык, предприятиеләр һәм оешмалар коллективлары белән аңлату эшләре алып бару;

- наркотиклы кыргый үсемлекләрнең үсү учакларын ачыклау һәм юк итү чаралары планын үтәү;

- наркотиклар, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы торуга, шул исәптән әлеге әйләнешне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү;

- эшче төркем вәкаләтләре чикләрендә наркотиклар, психотроп матдәләр әйләнеше турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган башка бурычлар.

III. Эшче төркемнең хокуклары

6. Шәрләрәмә авыл җирлеген оештыруга, координацияләүгә һәм үзара хезмәттәшлекне камилләштерүгә кагылышлы карарлар үз компетенциясе чикләрендә кабул итәргә

7. Татарстан Республикасы территориясендә наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы эшчәнлек алып баручы субъектлар белән.

8. Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә наркотик матдәләрнең, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы эшчәнлек алып баручы дәүләт органнары һәм башка субъектлар җитәкчеләреннән эшче төркем эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга.

IV. Эшче төркемнең эш тәртибе

9. Эшче төркем үз эшчәнлеген планлы нигездә алып бара. Эшче төркем эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү Шәрләрәмә авыл җирлеге хакимияте тарафыннан гамәлгә ашырыла

10. Эшче төркем утырышлары елына кимендә ике мәртәбә, июнь-сентябрь айларында үткәрелә. Кирәк булган очракта эш төркеме рәисе карары белән эш төркеменең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

11. Эш төркеме утырышында аның әгъзаларының катнашуы мәҗбүри.

12. Утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда эш төркеме әгъзалары тигез хокукларга ия.

13. Эш төркеме әгъзалары үз вәкаләтләрен башка затларга тапшырырга хокуклы түгел. Эш төркеме әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта, ул бу хакта эш төркеме рәисенә алдан хәбәр итә.

14. Эшче төркем утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

15. Карала торган мәсьәләләрнең үзенчәлегенә карап, эшче төркем утырышларында катнашуга башка затлар да җәлеп ителергә мөмкин.

16. Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул эшче төркем рәисе тарафыннан имзалана.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 27.08.2026
№ 10 карарына
3 нче кушымта

2026-2027 елларга Татарстан Республикасы Сарман районы Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә наркотиклы кыргый үсемлекләр үсү учакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары планы

| № | Чаралар исеме | башкару срогы | башкару турында тамга |
|---|---|---|---|
| 1 | Эш төркеме утырышы, наркотиклы үсемлекләрнең законсыз үсүе турында кергән белешмәләрне һәм мөрәҗәгатьләрне анализлау | Июнь - сентябрь чорында ай саен, калган чорда елга ике тапкырдан да сирәгрәк түгел | |
| 2 | Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясен наркотиклы кыргый үсемлекләрнең үсү учакларын ачыклау өчен тикшерү | д.Шәрләрәмә: июнь – сентябрь. д.Сөлек: июнь – сентябрь. д.Кормаш: июнь – сентябрь | |
| 3 | Кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрнең ачыкланган үсү учакларын юкка чыгаруга ярдәм күрсәтү | Ачыкланганнан соң кичекмәстән | |
| 4 | Кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрнең үсү учакларын юкка чыгару нәтиҗәләрен мониторинглау | Кыргый үскән нарколы үсемлекләрне юкка чыгарганда эшче төркем әгъзаларының турыдан-туры катнашуы | |
| 5 | Кешеләр күпләп җыела торган урыннарда наркотик чаралар куллануның куркынычы турында мәгълүмати материаллар урнаштыру | Даими | |
| 6 | Кыргый үсә торган наркотиклы үсемлекләрнең үсү учакларын юкка чыгару чараларын күрмәгән өчен | Ачыкланганнан соң кичекмәстән | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җаваплылык турында авыл хуҗалыгы предприятиеләре, башка оешмалар җитәкчеләренә мәгълүмат җиткерү | | |